КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

БОЕРЫК
2019 елның 26 августы, № 55-п

“Татмедиа” республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгында норматив хокукый актларга һәм
норматив хокукый актлар проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында”
“Татмедиа” республика матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2016 елның 3 ноябрендәге 36-п боерыгы белән расланган
“Татмедиа” республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгында норматив хокукый актларга һәм
норматив хокукый актлар проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә
үзгәреш кертү турында

“Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 1 октябрендәге 891 номерлы карарын үтәү максатыннан боерык бирәм:

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында” “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2016 елның 3 ноябрендәге 36-п боерыгы белән расланган “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә, аны түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә)

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
беренче урынбасар Э. Ф. Әхмәтова

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2019 елның “26” августы 55-п номерлы боерыгы белән РАСЛАНДЫ

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

1. “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең әлеге тәртибе (алга таба – тәртип) «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнде һәм “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза һәм аларны куллану мониторингын уздырганда әлеге норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасын билгели.

2. Коррупциягә каршы экспертиза Агентлыкның структур бүлекчәләре тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актларга (алга таба – норматив хокукый актлар) һәм норматив хокукый актлар проектларына (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) үткәрелергә тиеш.

Үз көчен югалткан дип танылган һәм юкка чыгарылган норматив хокукый актларга карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелми.

3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты – норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү.

Агентлыкта норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар

проектларына коррупциягә каршы экспертиза оештыруның төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең мәҗбүрилеге;

2) норматив хокукый актны (норматив хокукый акт проектын) башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнештә бәяләү;

3) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең дәлилле, объектив, тикшерелгән булуы;

4) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертизасын үткәрүче затларның компетентлылыгы;

5) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә Агентлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеге.

4. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән расланган аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе, әлеге Тәртип нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән методикага (алга таба - методика) таянып Агентлыкның юридик секторы мөдире тарафыннан үткәрелә.

5. Агентлыкның норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе тарафыннан эшләнгән норматив хокукый акт проекты хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен электрон документлар әйләнеше системасы буенча Агентлыкның юридик секторына җибәрелә.

6. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза әлеге проект Агентлыкның юридик секторына электрон документлар әйләнеше системасы буенча кергән көннән алып биш эш көненнән дә артмаган срокта гамәлгә ашырыла.

7. Норматив хокукый акт проекты электрон документлар әйләнеше системасы буенча Агентлыкның юридик секторына кергән көннән алып биш эш көне узганчы коррупциягә каршы үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә кушып бирелүче форма нигезендә бәяләмә (1 нче кушымта) язылa, ул Агентлыкның юридик секторы мөдире тарафыннан имзалана.

Бәяләмәдә түбәндәге мәгълүматлар чагылдырыла:

– экспертизага тәкъдим ителгән норматив хокукый акт проектының реквизитлары;

– норматив хокукый акт проектында коррупциячел факторлар булу яисә булмау;

– норматив хокукый акт проектының коррупциячел факторлар булган конкрет нигезләмәләре (коррупциячел факторларны ачыклаганда);

– норматив хокукый акт проекты нигезләмәләре формулировкаларын үзгәртү яисә коррупциячел факторларны бетерү өчен аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр (коррупциячел факторлар ачыкланганда).

Бәяләмә]язылганнан соң бер эш көне дәвамында Агентлыкның норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә җибәрелә.

8. Агентлыкның норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе, Агентлыкның коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциячел факторлар күрсәтелгән юридик сектор бәяләмәсен алган очракта, проектны җиде эш көне эчендә эшләп бетерә һәм эшләп бетерелгән норматив хокукый акт проектын кабат карау өчен Агентлыкның юридик секторына җибәрә. Коррупциягә каршы кабат экспертиза өч эш көне эчендә үткәрелә.

Норматив хокукый акт проектында коррупциячел факторлар булмаганда, Агентлыкның норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе норматив хокукый акт проектын Агентлыкның юридик секторы бәяләмәсе белән бергә гомуми бүлеккә җибәрә.

9. Агентлыкның норматив хокукый актларына һәм аларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, әлеге документларны әзерләүче аларны гомуми бүлеккә җибәрә, әлеге бүлек документларны Агентлыкның юридик секторына җибәрү көненә туры килә торган эш көне дәвамында Агентлыкның “Татарстан Республикасы рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә эшли торган рәсми сайтында (алга таба – агентлык сайты) һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм гавами фикер алышу уздыру максатларында норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру өчен бердәм региональ интернет-порталы (алга таба – бердәм региональ интернет-порталы) тарафыннан билгеләнгән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм гавами фикер алышу уздыру максатларында норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсында (http://tataratan.ru/regulation) урнаштыра.

Норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен урнаштырганда, проектны әзерләүче тарафыннан эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адрес (шул исәптән электрон почта адресы), бәйсез экспертиза үткәрүнең сроклары турында мәгълүмат, проект буенча тәкъдимнәр кертү, шулай ук бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлану даталары, тапшырылган эксперт бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрне җыю, гомумиләштерү һәм исәпкә алу өчен җаваплы белгечләр (норматив хокукый актлар проектлары буенча эксперт бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрен җибәрү өчен аларның телефон номерларын һәм электрон почта адресларын күрсәтеп) исемлеге күрсәтелә.

Шул ук вакытта Агентлыкның норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен урнаштыру срогы Агентлык сайтында һәм бердәм региональ интернет-порталында урнаштырган көннән алып

кимендә биш эш көне булырга тиеш, моңа Агентлыкның эшчәнлек өлкәсенә караган дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар керми, административ регламент проектлары өчен әлеге срок аларны Агентлык сайтында һәм бердәм региональ интернет-порталында урнаштырган көннән алып 15 көннән дә кимрәк булырга тиеш түгел.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләре яки конфиденциаль характердагы белешмәләр булган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

10. Агентлыкның норматив хокукый акт проектын (норматив хокукый акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проекты коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү максатларында урнаштырылган срок чикләрендә кергән бәяләмәне карый.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча бәяләмә кергән көнне, Агентлыкның норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе аны теркәү өчен гомуми бүлеккә җибәрә. Гомуми бүлек, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча бәяләмә кергән көннән соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча, аны электрон документлар әйләнеше системасында терки.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр тәкъдим итү характерында була һәм ул норматив хокукый акт проектын эшләүче тарафыннан аны алган көннән алып 15 көн эчендә мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яисә физик затка дәлилләнгән җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторлар турында мәгълүмат яисә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яисә) норматив хокукый актта (норматив хокукый акт проектында) ачыкланган коррупциячел факторлар белән килешмәүнең сәбәпләре бәян ителә.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр каралмый:

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән булса;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган тиешле формада булмаса.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган формага туры килмәсә, мондый бәяләмә, сәбәпләрен күрсәтеп, теркәлгән көннән алып 15 көннән дә соңга калмыйча кире кайтарыла.

11. Агентлыкның норматив хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза аларны куллану мониторингы (алга таба – мониторинг) уздырылганда

үткәрелә.

Мониторинг Агентлыкның юридик секторы һәм Агентлыкның норматив хокукый актлар эшләгән структур бүлекчәләре тарафыннан башкарыла.

12. Агентлыкның структур бүлекчәләре үзләре эшләгән норматив хокукый актка мониторинг үткәрү барышында хокук кулланучы өчен карауның нигезләнмәгән киң мәгънәләрен, гомуми кагыйдәләрдән чыгарылмаларны нигезсез рәвештә куллану мөмкинлекләрен, гражданнарга һәм оешмаларга карата билгесез, авыр үтәлешле һәм (яки) хокукны кыса торган таләпләр булуын таныклаучы шартлар ачыклаган очракта, норматив хокукый актка мониторинг үткәргәннән соң өч эш көне эчендә аны, дәлилләнгән нигезләрне бәян итеп, электрон документлар әйләнеше системасы буенча Агентлыкның юридик секторына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

Норматив хокукый актка коррупциягә каршы экспертиза ул электрон документлар әйләнеше системасы буенча Агентлыкның юридик секторына кергән көннән алып биш эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла, аның нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган тәртип буенча бәяләмә языла.

13. Агентлыкның юридик секторы бәяләмәсе нигезендә, Агентлыкның норматив хокукый актны куллану мониторингын гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе, Агентлыкның норматив хокукый актында ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү максатларында, бәяләмә алынган көннән алып эш көннәрендә санала торган җиде көн эчендә тиешле норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында әлеге Тәртип нигезендә норматив хокукый акт проектын әзерли һәм Агентлыкның юридик секторына җибәрә.

14. Норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциячел факторлар Агентлыкның норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе тарафыннан норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү стадиясендә бетерелә.

Коррупциягә каршы экспертиза үткәрелгәннән соң норматив хокукый акт проектына аны эшләүче тарафыннан үзгәрешләр кертелгән очракта, норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы экспертиза кабат үткәрелергә тиеш.

15. Хокук куллану мониторингы кысаларында норматив хокукый актка үткәрелгән коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә торган тиешле мәгълүмат составына кертелә.

16. Агентлык эшләнелә торган норматив хокукый актлар проектлары буенча гавами фикер алышуны тәэмин итә.

17. Гавами фикер алышу максатларында норматив хокукый актлар проектлары бердәм региональ интернет-порталга урнаштырыла.

18. Гавами фикер алышу өчен бердәм региональ интернет-порталга гражданнарның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы норматив хокукый актлар проектлары урнаштырыла.

19. Гавами фикер алышу өчен түбәндәгеләр урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итүче яисә конфиденциаль характердагы белешмәләре булган норматив хокукый актлар проектлары;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) үз көчләрен югалткан дип тану турында норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән эшләү вакыты гавами фикер алышуның минималь срогыннан кимрәк булган норматив хокукый актлар проектлары (бердәм региональ интернет-порталда урнаштырылган көннән соң биш эш көненнән кимрәк);

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яисә чыгымнарына йогынты ясый торган норматив хокукый актлар проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт хакимияте органнарының террорчылыкка шул исәптән террорчылыкны финанслауга каршы көрәш чараларын тормышка ашырганда эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларның үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен регламентлаучы норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актлар проектлары;

суд карарларын, прокурор реакциясе актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатларында әзерләнгән норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентлары һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентлары проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында норматив хокукый актлар проектлары.

20. Гавами фикер алышуны тәэмин итү өчен норматив хокукый актлар проектларын урнаштырганда, проект эшләнгән структур бүлекчә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адрес (шул исәптән электрон почта адресы), шулай ук гавами фикер алышуның башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

21. Норматив хокукый актлар проектлары буенча гавами фикер алышуы срогы бердәм региональ интернет-порталда урнаштырылганнан соң биш эш көненнән дә ким булмаска тиеш.

22. Әгәр проект эшләнгән структур бүлекчә тарафыннан норматив хокукый акт проектын гавами фикер алышу нәтиҗәләре буенча эшләп бетерү турында карар кабул ителгән булса, эшләнеп беткән норматив хокукый акт проекты шулай ук гавами фикер алышу өчен урнаштырыла.

23. Бердәм региональ интернет-порталда норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү срогы, гавами фикер алышу

срогы тәмамланган көннән алып 30 көн эчендә норматив хокукый актны (норматив хокукый акт проектын) эшләү өчен җаваплы зат коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү барышында ачыкланган коррупциячел факторлар турында җыелма мәгълүматны, гавами фикер алышу вакытында кергән тәкъдимнәрне, аларны карау нәтиҗәләрен күрсәтеп, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча урнаштыра.

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 1 нче кушымта

коррупциягә каршы экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча
бәяләмә

___________________________________________________________________________
(норматив хокукый актның /
норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы юридик секторы тарафыннан «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру кагыйдәләре һәм «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә

___________________________________________________________________________
(норматив хокукый актның / норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

коррупциячел факторларны ачыклау һәм аларны бетерү максатларында экспертиза үткәрелде.

1 вариант:

___________________________________________________________________
(норматив хокукый актның / норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

коррупциячел факторлар ачыкланмады.

2 вариант:

___________________________________________________________________

(норматив хокукый актның / норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

түбәндәге коррупциячел факторлар ачыкланды: ___________________________

__________________________________________________________________.

(норматив хокукый акт проектының коррупция факторлары булган конкрет нигезләмәләре күрсәтелә)

Ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

__________________________________________________________________

(коррупциячел факторларны бетерү ысуллары күрсәтелә:

__________________________________________________________________

норматив хокукый акт проекты нигезләмәләре формулировкасын үзгәртү

__________________________________________________________________

(проект текстын башка редакциядә бәян итү, проект текстына үзгәрешләр кертү,

__________________________________________________________________

норматив хокукый актны, аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру яисә башка ысуллар

__________________________________________________________________.

______________________ _________ _____________________ "___"__ 20__ ел.

(вазыйфаның исеме) (имза) (фамилияне тутырып язу)

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 1 нче кушымта

**Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм (яки) гавами фикер алышу нәтиҗәләре буенча җыелма**
**мәгълүмат**
**“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының**______________________________________________
(акт яки акт проекты исеме)

| Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза | | | |
|---|---|---|---|
| Т/с | Эксперт (ф. и. атасының исеме (соңгысы – булган очракта)/ аккредитация турында боерык реквизитлары) | Ачыкланган коррупциячел фактор | Эшләүченең шәрехләре |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Гавами фикер алышу | | | |
| Т/с | Фикер алышуда катнашучы (ф. и. атасының исеме (соңгысы – булган очракта)/ электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучының позициясе | Эшләүченең шәрехләре |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Өлешчә исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Исәпкә алынмаган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |